**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 ноябрендәге 3849 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 2 февралендәге 355 номерлы «Казан шәһәрендә халыкның тормыш, хезмәт дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү чаралары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәрендә халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, рәсми булмаган хезмәт базарын кыскарту һәм икътисадтагы тискәре тенденцияләрне җиңеп чыгу буенча алга таба эш алып баруны тәэмин итү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 2 февралендәге 355 номерлы «Казан шәһәрендә халыкның тормыш, хезмәт дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү чаралары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 19 гыйнварындагы 167 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3, 1.4, 2.1, 2.2, 3.2, 3.3, 5.1, 5.2 пунктларда «2022-2023 елларга» сүзләрен «2024-2025 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2 пунктта «Р.Р.Шәфигуллинга,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Г.Р.Сәгыйтовага» сүзләрен «А.И.Абзаловка» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3 пунктта «Ф.В.Нурмөхәммәтовка, М.Ф.Закировка, С.А.Мироновка, Р.Р.Фәтхетдиновка» сүзләрен «Р.Х.Шәмсетдиновка, А.И.Салиховка, В.В.Жаворонковка, Р.Р.Фәтхетдиновка» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 5 пунктта «вазифалар башкаручы Г.Р.Минһаҗева» сүзләрен «Г.Р.Минһаҗева» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 1 номерлы кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

1.6. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 2 февралендәге 355 номерлы карарына 1 номерлы кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 ноябрендәге
3849 номерлы карарына
кушымта

**Халыкның тормыш, хезмәт дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча шәһәр комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Гафаров Рөстәм Гыйльфан улы | комиссия рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе |
| Шакиров Илдар Сәетҗан улы | комиссия рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Минһаҗева Гүзәл Рафаил кызы | комиссия сәркатибе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитеты рәисе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Нигъмәтҗанов Азат Роберт улы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Гыйниятуллин Искәндәр Әнвәр улы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Куляжев Игорь Владимирович | Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Абзалов Азат Искәндәр улы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Алиев Булат Рафаил улы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе |
| Шәмсетдинов Ренат Харрас улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе башлыгы |
| Салихов Альберт Иршат улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы |
| Жаворонков Владимир Владимирович | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы |
| Фәтхетдинов Роман Рәмиз улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе башлыгы |
| Графова | Казан шәһәрендә дәүләт статистикасы бүлеге |

| | |
|---|---|
| Алина Игоревна | (килешү буенча) |
| Муллин Тимур Фәһим улы | «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Казанцев Владимир Анатольевич | Казан шәһәре Думасы аппаратының мәгълүмат-аналитика идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Рассман Игорь Олегович | Эш белән тәэмин итүчеләрнең «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» төбәк берләшмәсе генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Арикова Гүзәл Рәшит кызы | Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе карамагындагы 3 номерлы камераль контроль бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сидорова Наталья Юрьевна | Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе социаль фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсенең иминият кертемнәрен персональләштерелгән исәпкә алуны оештыру һәм алар белән идарә итү бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Столяров Станислав Олегович | Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенең аеруча мөһим эшләрне тикшерү буенча дүртенче бүлек җитәкчесе (килешү буенча) |
| Нуриева Венера Нурмөхәммәт кызы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге профсоюзлар оешмаларының координация советы рәисе (килешү буенча) |